| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2020 п.г.т.Алексеевское № 153

**«Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү турында» 2018 елның 08 маендагы 122 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән

**карар кылам:**

1. «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2018 елның 08 маендагы 122 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының түбәндәге эчтәлекле карарына үзгәреш кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү, алар Административ хокук бозулар турында Кодекснын 2.1, 2.4-2.8, 2.12-2.15, 2.16, 2.17 3.2-3.8, 3.10, 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 маддәләрендә каралган (кушымта)»;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә

| Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы статьялары аталышы (алга таба ТР КоАП) | Вазыйфаи затлар исемлеге |
| --- | --- |
| **ТР КоАП 2.17 маддә**<br>Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлар таләпләрен үтәмәү | - «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе;<br>- район башлыгы урынбасары (килешү буенча);<br>- Советның коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча башлыгының ярдәмчесе (килешү буенча);<br>- Советның оештыру бүлеге башлыгы;<br>- Советның гомуми бүлеге башлыгы (килешү буенча);<br>- Икътисад буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;<br>- башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы;<br>- инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары;<br>- башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;<br>- башкарма комитетның инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;<br>- башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;<br>- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;<br>- башкарма комитетның мәгариф бүлеге башлыгы урынбасары<br>- башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе;<br>- башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;<br>- социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);<br>- башкарма комитетның архив бүлеге башлыгы;<br>- башкарма комитетның эшләр идарәчесе;<br>- башкарма комитетның гомуми бүлеге җитәкчесе;<br>- шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре һәм |

| | |
|---|---|
| | секретарьлары (килешү буенча);<br>- Шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча). |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.В.Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**